**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел,14 декабрь №14

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 46 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 9нчы ноябрендәге, № 363-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлеге муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 12 маендагы 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3)Гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен узем тикшереп торам.

**Иске Йомралы авыл
җирлеге Башлыгы** **Р.А. Моратов**